**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет
Какре-Елгинского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района

423320, Азнакаевский район,
с.Какре-Елга, ул.Советская, д.22
тел.8(855-92)37-0-49
E-mail:Kelg.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАС**

Азнакай муниципаль районы
Кәкре-Елга авыл җирлеге
башкарма комитеты

423320, Азнакай районы,
Кәкре-Елга авылы, Совет урам
22
тел.8(855-92)37-0-49
E-mail:Kelg.Azn@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

« 09» августа 2019 г. — № 33

Татарстан Республикасы А знакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мерәҗәгатьләргә анализ үткәрү Тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясе гражданнары мерәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 02.05.2006 ел 59-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мерәҗәгатьләре турында» 12.05.2003 ел №16-ТРЗ Татарстан Республикасы законы» нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитеты карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирелеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мерәҗәгатьләргә анализ үткәрү Тәртибен расларга (№ 1 кушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык И.М.Мехәмәтҗанов

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма
комитеты карарына кушымта
№1 09.08.2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип 12.05.2003 ел № 16-ТРЗ «Татарстан Республикасында гражданнар мерәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсен үтәү йөзеннән эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мерәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау, гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау, җәмәгатьчелек фикерен һәм актуаль проблемаларны өйрәнү, гражданнар мерәҗәгатьләре белән эшләү формаларын һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатыннан үткәрелә.

3. Тиешле чорда гражданнардан кергән мерәҗәгатьләрне анализлау барлык мерәҗәгатьләр, шул исәптән язма рәвештә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү аша җибәрелгән электрон документ формасында, шулай ук вәкаләтле затларның гражданнарны кабул итү барышында кабул ителгән мерәҗәгатьләр буенча гамәлгә ашырыла.

4. Кергән мерәҗәгатьләрне анализлау ел саен башкарыла.

5. Гражданна р мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитеты сәркатибе хисап чорыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр аналитик белешмә төзи.

6. Аналитик белешмәдә шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар һәм күчмә кабул итү, мерәҗәгатьләрнең тематикасы, мерәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында (булган очракта) мәгълүмат булырга тиеш.

7. Җирле үзидарә органнарына кергән гражданнарның мерәҗәгатьләренә Анализ тиешле чорда узган елның шул ук чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитет сәркатибе еллык аналитик белешмәне Азнакай муниципаль районының Интернет-мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында ел саен түбәндәге веб-адрес буенча : http://aznakayevo.tatarstan.ru “Гражданнар мерәҗәгете” бүлегендә бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштыруны тәэмин итә.